**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Зур Сукаеш авылы № 30 10 октябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (29.11.2016 № 23, 05.09.2017 № 13, 11.09.2017 № 16, 18.07.2018 №17, 11.09.2018 № 23 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль берәмлегенең «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә

Сукаеш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (29.11.2016 № 23, 05.09.2017 № 13, 11.09.2017, №16, 18.07.2018 №17, 11.09.2018 № 23 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 36 статьяга. Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары:

- Индивидуаль торак йортлар белән торак төзелешенең территориаль зонасы өчен шәһәр төзелеше регламентларына күчемсез милекне файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата җир кишәрлекләренең максималь чик күләмнәрен билгеләү өлешендә үзгәреш кертергә - 5000 кв.м».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Закирова З.Ж.